# Бәйләнешле сөйләм үстерү. Укучыларны сочинение-фикерләмә язуга әзерләү

***Уйларыбыз ак кәгазьдә…***

# Сочинение-фикерләмә язуга таләпләр

**Сочинение-фикерләмә** – билгеле бер фикерне дәлилләп язылган текст.

Анда ***төп 3 элементның*** булуы таләп ителә.

- **тезис** – ***дәлилләр*** белән расланырга тиешле төп фикер;
- **аргументлар** – укылган тексттан ***дәлилләр***, мисаллар;
- **нәтиҗә** – ***аргументлар*** ярдәмендә ***дәлилләнгән тезис***.

Мондый сочинениедә, белгәнебезчә, ***3 абзац*** булырга тиеш.

# Сочинение-фикерләмәне язганда истә тотыйк!

**1**.Тезис буларак китерелгән ***җөмләләрнең мәгънәсен текстка бәйле рәвештә аңлатырга кирәк.***

**2.**Тексттан ***ике мисал-дәлил китерелергә тиеш*** (алар икесе дә укылган материалдан алына)

**3**. ***Композицион*** төзеклек: ***кереш, башлам яки йомгак өлешләрнең берсен дә төшереп калдырырга ярамый.***

**4**. ***Кызыл юлларга*** бүленеш дөрес бирелергә яки 3 өлеш арасында ***бәйләнеш*** сакланырга тиеш. **5**. Сочинение-фикерләмә ***тезиска*** карарга тиеш ***(бөтенләй башка темага*** язылган очракта эш тикшерелми).

**Истә тотыйк: сочинение язганда текстның *эчтәлеген* түгел, ә *идеясен* анализлап язарга кирәк.**

# Төп өлеш

- Төп өлеш күләме ягыннан кереш һәм йомгактан зуррак була. Сочинениенең бу өлешендә текстны сөйләп чыгудан, темага туры килмәгән мәгълүматларны язудан качарга кирәк. Төп өлештә үз фикереңне логик дәлилле һәм стилистик хаталарсыз язу осталыгы күрсәтелә. Тезиста чагылган фикернең дөреслеге дә дәлилләнә. Моның өчен, текстны берничә тапкыр укырга, аның темасын (текст нәрсә турында?), идеясен (автор нәрсә әйтергә тели?) белгеләргә кирәк. Гадәттә, текстның идеясе нәкъ менә бирелгән өзектә чагыла. Тексттан, бу идеяне дәлилли торган җөмләләрне табып, аларның мәгънәсен үз сүзләрең белән аңлатып язарга кирәк. Бу - эчтәлек сөйләп чыгу гына түгел, ә

# Текст өстендә эш

“Кыядагы ояда” *(Ф. Яруллиннан)* чыганак тексты буенча эшне башлыйк. *(Эш төркемнәрдә оештырыла)*

Сезнең алда сочинение-фикерләмә язганда файдаланырга мөмкин булган *клише-шаблоннар.*

Текстның эчтәлеге белән танышыйк.

# Кыядагы ояда

(1) Биек тау башында бер бөркет оясы бар икән. (2) Язгы таңда ул ояда берсеннән-берсе матур өч бала дөньяга килгән. (3) Әнкә бөркет көннәр буе җим ташыган, балаларын җил-давылдан саклаган. (4) Ә беркөнне, көчле давыл вакытында, ул һәлак булган.

(5) Бөркетнең балалары әниләрен көн-төн көткәннәр, тәмам хәлсезләнгәннәр. (6) Оя янындагы зур таш астында Кара елан яшәп ята икән. (7) Ул бөркет балаларының елаганын ишеткән.

(8) - Ярар, - дигән Кара елан, - мин сезне үскәнче ашатып торырмын. (9) Ләкин минем бер шартым бар...

(10) Шушы көннән Кара елан бөркет балаларын ашата башлаган. (11) Ниһаять, бөркет балалары үсеп җиткәннәр. (12) – Рәхмәт сиңа, Кара елан, - син безне ашаттың, үстердең. (13) Инде шартыңны әйт, - дигән алар.

(14) – Шартым шул: берегез канатларыгызны, икенчегез – күзләрегезне, өченчегез тәпиләрегезне бирегез.(15) Бөркетләр, яшертен генә, әле - бер-берсенә, әле Кара еланга күз салганнар һәм качарга уйлаганнннар.(16) Кара елан, бөркетләрнең уйларын сизенеп, болай дигән:

- Әлбәттә, сез хәзер еракка-еракка очып китә аласыз. (17) Кая гына китсәгез дә, мин куа бармам. (18)Тик шуны онытмагыз: аучы укларыннан, яшен утларыннан качып котыла алсагыз да, үзегездән кача алмаячаксыз. (19) Намусыгыз сезне һәрвакыт эзәрлекләп йөрер. (20) Ә минем өчен борчылмагыз. (21) Үлгәнче, җирдә бер яхшылык эшләп калдырасым килгән иде. (22) Хәзер минем җаным тыныч. (23) Кара еланнарның да күңелләре ак икәнлеген раслый алдым.

(24) Бөркетләргә бик-бик оят булган. (25) Берсе - канатларын, икенчесе - күзләрен, өченчесе тәпиләрен Кара еланга китереп биргәннәр. (26) Ләкин елан бөркетләрнең кадерле нәрсәләрен үзләренә кайтарып биргән. (27) Бөркетләр, аңа мең рәхмәтләр укып, һавага күтәрелгәннәр.

(28) - Кайда гына йөрсәгез дә, нинди юллар үтсәгез дә, шуны исегездә тотыгыз: эшнең шартын белми торып, вәгъдә бирергә ашыкмагыз. (29) Вәгъдәне бирү җиңел, ләкин үтәве

# Бирем

**11.1. Кайда гына йөрсәгез дә, нинди юллар үтсәгез дә, шуны исегездә тотыгыз: эшнең шартын белми торып, вәгъдә бирергә ашыкмагыз. Вәгъдәне бирү җиңел, ләкин үтәве авыр. Вәгъдә - күңелнең иманы** ***җөмләләрендә әйтелгән фикерләрне аңлатып, сочинение языгыз. Укылган тексттан фикерләрегезне раслый торган 2 дәлил китерегез. Файдаланган җөмләләрнең номерларын күрсәтегез  яки тулысынча языгыз.  Сочинениенең күләме 50 сүздән ким булмаска тиеш. Укылган текстка таянып язылмаган эшкә билге куелмый.     Текстны күчереп яисә аның эчтәлеген аңлатмаларсыз язган өчен, ноль балл куела.***

# Кереш өлеш

***Кереш*** өлешне дөрес формалаштырыйк. Бу – иң мөһим өлеш, чөнки сочинениенең дөрес килеп чыгуы шуңа бәйләнгән.

***(клише-шаблон)*** - **Тәкъдим ителгән тезиста автор безне ................ турында уйланырга чакыра. Мин дә автор фикере белән килешәм (яки килешмим). Вәгъдәдә тору - ............. дигән сүз.**

***Кереш өлешне формалаштыргач, үз төркемеңдә тикшерү эше башкарыла. Аннары һәр төркем үзенең язмасы белән таныштырып чыга һәм гомуми фикергә киләбез.***

# Кереш өлешне формалаштыруның якынча үрнәге

Тәкъдим ителгән тезиста Ф.Яруллин безне вәгъдә бирү, сүзеңдә тора белү кебек рухи кыйммәтләр турында уйланырга чакыра. Мин автор фикере белән килешәм. Вәгъдәне онытмау, ягъни әйткән сүздә тору, үз ризалыгың белән алынган йөкләмәне үтәү ул.

# Төп өлеш

***Төп өлешне*** **шартлы рәвештә** ***икегә*** **бүлеп карарга мөмкин.**

**1 . Проблеманы дәвам итү һәм тексттан өзекнең** ***идеясен*** **билгеләрлек** ***аргументны*** **дөрес табу.**

**Автор, беренчедән, нинди төп фикерне җиткерә, ягъни проблема нәрсәгә нигезләнеп ачыла? – (*клише-шаблон) -* Текстта бирелгән вакыйга .......... кирәклеген искәртә. Бу.... нче җөмләдә күрсәтелә.**

# Төп өлеш

2 . **Шушы табылган *аргументны дәлилләү, ачыклау*:**

(***клише-шаблон***) **- Вәгъдә бирү – ............... . Аны үтәү, ................... - иң мөһиме. Вәгъдәсен үтәмәгәннәрне................. көтә. Әлеге фикер....... нчы җөмләдә раслана. Кемгә дә булса сүз бирер алдыннан........................ . Кара еланның сүзләре.................яңгырый .**

# Төп өлешне формалаштыруның якынча үрнәге

Вәгъдәгә җаваплы карарга кирәклеге текстта Кара елан һәм бөркет балалары арасындагы вакыйга аша бирелә. Ашыгып, шартын белми әйткән сүз аркасында, бөркет балалары кебек иң кадерле нәрсәләреңнән колак кагарга да мөмкин. Бу турыда 13 нче җөмләдә әйтелә. Вәгъдә бирү – эшнең башы гына. Аны үтәү, биргән сүзеңдә тору - иң мөһиме. Вәгъдәсен үтәмәгәннәрне вөҗдан газабы көтә. Әлеге фикер 19 нчы җөмләдә раслана. Кемгә дә булса сүз бирер алдыннан яхшылап уйларга кирәк. Ак күңелле Кара еланның гыйбрәтле сүзләре безгә дә сабак булып яңгырый.

# Йомгак өлеше

***Йомгак өлешен*** **формалаштыру:**

**Дәлилләнгән фикергә ничек йомгак ясыйбыз? – (*клише-шаблон*) - Димәк (шулай итеп), автор безне......өнди. Әйе, ............ .**

# Йомгак өлешне формалаштыруның якынча үрнәге

Димәк, автор безне биргән вәгъдәбезне үтәргә, кешелекле , иманлы булып калырга өнди. Әйе, тормышта үз кыйблаңны табып, дөрес яшәргә кирәк.

# Мастер-класcның йомгаклау этабы

Язманың 3 өлеше дә тәмамлангач, һәр төркемдәге укучылар сочинение-фикерләмәне бергә камилләштерә, хаталарны орфографик сүзлек кулланып төзәтә, укытучыга һәм башка төркемдәгеләрне язмасы белән таныштыра.

Гомуми фикер алышу. Экрандагы әзер сочинение-фикерләмә белән чагыштыру. Һәр төркем үзенең эшен бәяли.

# Якынча үрнәк сочинение-фикерләмә

**Тәкъдим ителгән тезиста Ф.Яруллин безне вәгъдә бирү, сүзеңдә тора белү кебек рухи кыйммәтләр турында уйланырга чакыра. Мин автор фикере белән килешәм. Вәгъдәне онытмау - үз ризалыгың белән алынган йөкләмәне үтәү ул.**

**Бу фикер текстта Кара елан һәм бөркет балалары арасындагы вакыйга аша бирелә. Ашыгып, шартын белми әйткән сүз аркасында, бөркет балалары кебек иң кадерле нәрсәләреңнән колак кагарга да мөмкин. Бу турыда 13 нче җөмләдә әйтелә. Вәгъдә бирү – җиңел, аны үтәү, биргән сүзеңдә тору - иң мөһиме. Вәгъдәсен үтәмәгәннәрне вөҗдан газабы көтә. Әлеге фикер 19 нчы җөмләдә дәлилләнә. Кемгә дә булса сүз бирер алдыннан яхшылап уйларга кирәк. Кара еланның гыйбрәтле сүзләре безгә сабак булып яңгырый.**

**Димәк, автор безне биргән вәгъдәбезне үтәргә, кешелекле булып калырга өнди. Әйе, тормышта үз кыйблаңны табып, дөрес яшәргә кирәк.**